**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 16 маендагы 1524 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 25 ноябрендәге 10204 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Заказ бирүчеләр, муниципаль заказ бирүчеләр һәм Казан шәһәренең муниципаль автоном учреждениеләре ихтыяҗлары өчен сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия составы үзгәрүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 25 ноябрендәге 10204 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 7 февралендәге 601 номерлы, 2014 елның 22 апрелендәге 2172 номерлы, 2014 елның 12 декабрендәге 7157 номерлы, 2015 елның 6 мартындагы 1452 номерлы, 2015 елның 8 июнендәге 2307 номерлы, 2015 елның 30 октябрендәге 3836 номерлы, 2016 елның 17 ноябрендәге 4671 номерлы, 2016 елның 29 декабрендәге 5397 номерлы, 2017 елның 4 апрелендәге 987 номерлы, 2017 елның 25 апрелендәге 1439 номерлы, 2017 елның 5 сентябрендәге 3414 номерлы, 2018 елның 25 гыйнварындагы 199 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 2125 номерлы, 2018 елның 11 июлендәге 3878 номерлы, 2018 елның 18 сентябрендәге 4986 номерлы, 2018 елның 20 ноябрендәге 5893 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы 1128 номерлы, 2019 елның 21 ноябрендәге 4150 номерлы, 2020 елның 6 августындагы 2137 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 3313 номерлы, 2022 елның 28 апрелендәге 1268 номерлы, 2023 елның 8 августындагы 2237 номерлы, 2023 елның 22 декабрендәге 4282 номерлы, 2024 елның 9 апрелендәге 1413 номерлы, 2025 елның 18 апрелендәге 1240 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге

үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 25 ноябрендәге 10204 номерлы карарына 5 номерлы кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Казан шәһәренең конкурентлык сәясәте һәм сатып алулар буенча дирекциясе» муниципаль казна учреждениесе директорына йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2025 елның
16 маендагы 1524 номерлы
карарына кушымта

**Заказ бирүчеләр, муниципаль заказ бирүчеләр һәм Казан шәһәренең муниципаль автоном учреждениеләре ихтыяҗлары өчен сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Р.М.Мөдәррисов | комиссия рәисе, «Казан шәһәренең конкурентлык сәясәте һәм сатып алулар буенча дирекциясе» муниципаль казна учреждениесе директоры |
| Д.И.Гыйбадуллина | комиссия рәисе урынбасары, «Казан шәһәренең конкурентлык сәясәте һәм сатып алулар буенча дирекциясе» муниципаль казна учреждениесе директорының беренче урынбасары |
| Ф.И.Зарипов | комиссия рәисе урынбасары, «Казан шәһәренең конкурентлык сәясәте һәм сатып алулар буенча дирекциясе» муниципаль казна учреждениесе директоры урынбасары |
| **Комиссия әгъзалары**: | |
| Н.Н.Комиссарова | «Казан шәһәренең конкуренция сәясәте һәм сатып алулар дирекциясе» муниципаль казна учреждениесенең тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү бүлеге башлыгы |
| Г.В.Гужов | «Казан шәһәренең конкуренция сәясәте һәм сатып алулар дирекциясе» муниципаль казна учреждениесенең тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү бүлеге башлыгы урынбасары |
| И.Н.Маркелова | «Казан шәһәренең конкуренция сәясәте һәм сатып алулар дирекциясе» муниципаль казна учреждениесенең тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү бүлегенең сатып алулар буенча баш белгече |